# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Вольный Труд торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

27.10.2022 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Вольный Труд торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2022 елның 27 октябрендә 11:30 сәг уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2023 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Вольный Труд пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Урам утларын карап тоту, Вольный Труд авылы өчен урам яктырткычлары сатып алу, урнаштыру, ремонтлау һәм алыштыру, урам утлары өчен материаллар сатып алу буенча чаралар;

2. Су белән тәэмин итү өчен материаллар һәм электр товарлары ремонтлау, хезмәт күрсәтү, сатып алу, скважина өстендә павильон урнаштыру, килешү буенча башкарылган эшләргә түләү);

2. Вольный Труд торак пункты янындагы урман массивлары янәшәсендә юлларга хезмәт күрсәтү (кар чистарту), үләнне чабу, янгынга каршы минераллаштырылган полосаларны сөрү (дизель ягулыгы һәм май сатып алу, штаттан тыш хезмәткәргә хезмәт килешүе буенча хезмәт хакын түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 18 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 10 кеше, бу 55,6 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 10 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:
1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Вольный Труд торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.
2. 2023 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Вольный Труд торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.
3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:
– Урам утларын карап тору, электр товарлары сатып алу, урам яктырткычларын урнаштыру һәм алыштыру буенча чаралар;
– Халыкны су белән тәэмин итү, ремонтлау, хезмәт күрсәтү һәм су белән тәэмин итү өчен башка материаллар алу, килешү буенча башкарылган эшләргә түләү;
– Юлларга хезмәт күрсәтү, кар чистарту, үлән чабу, янгынга каршы минеральләштерелгән полосалар сөрү, дизель ягулыгы һәм май алу, хезмәт килешүе буенча штаттан тыш хезмәткәргә-тракторчыга хезмәт хакы түләү;
– Вольный Труд территориясенә хезмәт күрсәтүче хезмәткәргә килешү буенча хезмәт хакы түләү.
4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыены рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы М.С. Салихов